КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 2 июнь г.Казань № 762

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген һәм төгәлләнмәгән төзелеш объектын алу турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында Казан - Боровое Матюшино төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Орел авыл җирлеге адресы буенча урнашкан «ТАИФ» акционерлык җәмгыяте (алга таба – хокук иясе) милкендә булган авыл торак пунктлар җирләре категориясендәге 469 965 кв.метр мәйданлы 16:24:260201:3065 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 2 235 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген (алга таба – алына торган җир кишәрлеге) хокук иясенә алына торган җир кишәрлеге урынына Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлеген бирү юлы белән алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында Казан - Боровое Матюшино автомобиль юлын реконструкцияләү» төбәк әһәмиятендәге линия объектын урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне ызанлау проектын раслау турында» 2025 ел, 07 август, 572 нче карары белән расланган территорияне

планлаштыру проектын һәм территорияне ызанлау проектын исәпкә алып (алга таба - территорияне планлаштыру һәм ызанлау проекты), хокук иясе милкендә булган 16:24:260201:3876 кадастр номерлы төгәлләнмәгән төзелеш объектын - «Татарстан Республикасы Лаеш районында «ТАИФ» АҖ «Мәдәни-сәламәтләндерү комплексы»на автомобиль юлы» корылмасын алырга дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

3.1. 10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районындагы Орловка авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәсен хокук иясенә, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне.

3.2. Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген һәм тәмамланмаган төзелеш объектын алу турында килешү төзү.

3.3. Алына торган җир кишәрлегенә һәм төгәлләнмәгән төзелеш объектына Татарстан Республикасы милек хокукын дәүләт теркәвенә алу.

4. Татарстанның юл-транспорт идарәсе законнарда билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрне тәэмин итергә:

территорияне планлаштыру һәм ызанлау проекты нигезендә алына торган җир кишәрлегенә карата кадастр эшләрен үткәрү;

алына торган җир кишәрлеге һәм төгәлләнмәгән төзелеш объекты өчен каплау күләмен билгеләү;

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегенең базар бәясен билгеләү;

Татарстан Республикасы милкендәге алына торган җир кишәрлеге, төгәлләнмәгән төзелеш объекты һәм җир кишәрлегенең базар хакы өчен түләтү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген һәм төгәлләнмәгән төзелеш объектын алу турында килешү әзерләү һәм аның хокук иясенә җибәрү;

хокук иясе белән җир кишәрлеген һәм төгәлләнмәгән төзелеш объектын алган һәм имзаланган нөсхәне законнарда билгеләнгән срокта тапшырмаган очракта тиешле дәгъваны судка бирү.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин